# ТЕЛ - РУХИ БАЙЛЫГЫБЫЗ

**Максат:** 1) Туган телгә - ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләү;
2) телебезне сакларга һәм якларга кирәклеген төшендерү;

3) Туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү.

**Дәрес барышы.**

**I. Актуальләштерү.**

а) “Туган тел” көе яңгырый. Җырларга мөмкин.

б) Укытучының кереш сүзе.

**Укытучы:** Тел ул – бөтен халык казанышы, меңнәрчә, миллионнарча кешеләрнең күп гасырлык иҗат җимеше. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык, милләт югала. Туган телен саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы.

Без – татарлар, туган телебез – татар теле.

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, К.Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, иң иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган баш имәгән горур татар теле.

**II. Төп өлеш.**

- Дәресебезне сөекле Тукаебыз сүзләренә иҗат ителгән “Туган тел” җыры белән башладык. Туган телебезнең матур, нәфис, бай булуына кабат ышандык. “Әткәм-әнкәмнең теле”, - дигән сүзләргә тирән мәгънә салынганын аңладык.

Әйе, Г.Тукай туган телебезнең сихри моңнарын бар нечкәлекләре белән безгә җиткерүче шагыйрь.

Туган телебез – татар теле. Ул – бик борынгы һәм бик бай телләрнең берсе. Галимнәрнең әйтүенә караганда, әгәр кеше 14 телне белсә, дөньядагы барлык халыклар белән дә җиңел аралаша ала икән. Иң бай һәи иң күп таралган шул 14 телгә инглиз, испан, француз, итальян, кытай, гарәп, рус, татар теле дә керә.

Төрле телләр арасында татар теле сүзләренең байлыгы, сөйләм төзелешенең образлы булуы белән аерылып тора.

*Җыр тыңлау. “Әссәламегаләкем” Госман Садә сүз., Р.Ахиярова көе.*

**III. Әңгәмә.**

**Укытучы:** Бүген Россиядә һәм БДБ илләрендә татарлар өчен дистәләгән газета-журналлар чыга, радио телетапшырулар алып барыла. Алар телне, динне, гореф-гадәтләрне онытырга юл куймаячак.

Кеше һава суламыйча яши алмаган кебек милләт тә телсез яши алмый.

Милләт – теле булган халык ул. Ә милли телнең нигезе – ана теле.

- Туган телне без нинди тел дибез? (ана).
- Ни өчен? (Чөнки бу сүзләрне безгә кадерле әниебез өйрәткән һ.б.)

Укытучы: Әниләрне ничек яратсак, туган телне дә шулай яратырга кирәк.

*Җыр. “Әнкәмнең догалары” Р.Миңнуллин сүзләре.*

**IV. Тактада язылган мәкальләрне дәвам итеп язып бетерү.**

1. Тел – халыкның ... (горурлыгы)
2. Тел язмышы ... (милләт язмышы)
3. Тел тарихы – халык ... (тарихы ул)
4. Тел кайгыны ... (уртаклаша)
5. Әдәп башы ... (тел)
6. Тел – йөрәкләрне ... (кавыштыра), кешеләрне ... (дус итә).

**Укытучы:** Туган теле булган халыкның туган җире бар. Туган җиреннән аерылган халык теленнән дә аерыла. Татар халкы кайларда гына яшәсә дә, туган телен, туган илен саклап калырга омтылган. Балаларын, нәсел-нәсәбен дә шушы юнәлештә тәрбияләгән. Татар халкы ерак себергә куылганда да, сугыш авырлыкларын кичергәндә дә киләчәге өчен борчылып яшәгән. Теле, нәселе, Ватаны өчен һәрвакыт көрәштә булган. Кайда гына булса да, туган ягын, телен, туган илен сагынып яшәгән.

**V. Йомгаклау.**

**Укытучы:** Туган җирдә, туган телдә аралашып гомер итүнең нинди зур бәхет икәнлеген аңлатып тору кирәкмидер. Без моны элек тә яхшы белә идек... Шуңа күрә дә туган телне, динне, гореф-гадәтләрне, милли бәйрәмнәребезне саклау һәм үстерү, онытылганнарын яңадан тергезү безнең көндәлнк бурычыбыз булып кала. Бу турыда “Татарстан Республикасы дәүдәт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы”н, 2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын искә төшереп үсү максатка ярашлы булыр.

Класс сәгате ахырында Р.Миңнуллин сүзләренә язылган “Яратыгыз” җыры башкарыла.